БАРЫСЫ ДА ИСӘПТӘ
Татарстанда авыл халкының мөлкәтен санадылар

> 2

ЯЛГЫШМАС ӨЧЕН ТЫҢЛАРГА
Министрлыклар өстенлекле эш юнәлешләрен билгели

> 2

ТАЛӘПЧӘН, ӘММА ГАДЕЛ
Салих Батыевның туууына – 110 ел

> 3

«БЕЗ МОНДА БАРЫСЫН ДА КҮРӘБЕЗ»
Татарстан чемпионаты җиңүчеләре билгеле

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 171 (28753) | Чәршәмбе | 24 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ЮЛ – ТУЗАНСЫЗ, КЫШ КАРСЫЗ БУЛМАС

Юл эшләренең тынганы юк инде аның. Саннарга карасаң да, республика юлларын тәртипкә китерүгә шактый көч киткәнен аңларга була. Әйтик, 2021 елда юлларны төзү, төзекләндерү һәм рәткә китерү өчен 38,7 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Машина белән җилдереп үтәрлекләре дә, төзелеш эшләре тәгәлләнмәгән юл өлешләре дә бар әле. Кышка нинди нәтиҗәләр белән керәбез? Хөкүмәт йортында шул хакта сөйләделәр.

tatarstan.ru

Федераль программа булыша

Нигездә, Татарстан юлларын тәртипкә китерү «Имин һәм сыйфатлы юллар» илкүләм проекты ярдәмендә башкарыла. Аның кысасында Казан, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге юлларда төзекләндерү алып барыла. Гомумән алганда, шушы өч агломерация 2,5 меңнән артык чакрым юлны үз эченә ала. 2021 елда федераль программа нигезендә матди ярдәмнең күләме 12,186 млрд сумны тәшкил иткән.

– Максат итеп куйган эшләрне башкардык, – ди Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов. – Республика быел да илкүләм проектны тормышка ашыруда яхшы күрсәткечләргә ирешкән өчен бүләкләнде. Истәлекле дипломны 84 төбәкнең 11е алды.

Министр чыгышыннан аңлашылганча, төбәк әһәмиятендәге 96,7 чакрым озынлыкта 51 юл участогы төзекләндерелгән. Казан агломерациясенә кергән 61,6 чакрым озынлыктагы 32 участок яңартылган. Чаллы агломерациясенә караган 9 объектта төзекләндерү эше башкарылган (48,4 чакрым юл). Түбән Камага караган 11,1 чакрым юл тәртипкә китерелгән.

Борчылырга кирәкми

Министр әйтүенчә, юл хуҗалыгы кышка тулысынча әзерлекле булып аяк баса.

– Беренче кар-бураннар техниканың әзерлеген сынады. Борчылырга кирәкми. Юл хезмәте оешмалары карамагында 1157 берәмлек махсус техника бар, алар ГЛОНАСС системасына тоташкан. Аерым алганда, бу – 316 юл машинасы, 140 автогрейдер, 117 ротор һәм 497 берәмлек башка төр техника. Кышкы чорда юлларны тәртиптә тоту өчен 52 бозлавыкка каршы материал базасы, техника өчен 67 җылы тукталыш, юл эшчеләре һәм машина йөртүчеләр ялы өчен 59 бина каралган. Тайгак юлга сибәр өчен, 395 мең тонна тоз-ком кушылмасы, 79 мең тонна техник тоз әзерләнде, – диде Фәрит Хәнифов.

Һава торышы көйсез чакта юлга чыгу тыелачак. Бу – ел саен кулланыла торган тәҗрибә инде. «Кичке алтыдан иртәнге алтыга кадәр пассажир ташучы транспортны туктатып тора идек. Кыш – кыш инде ул. Бу куркынычсызлык өчен шулай эшләнә», – диде тармак башлыгы.

Җәен яңгыр коесы тулса, кышын юлда кар көртләре өелә. Башкала эчендәге юлларны ничек чиста тотарга җыеналар соң?

– Шәһәр юлларының озынлыгы 1950 чакрымны тәшкил итә. 21,5 млн кв. м мәйданны чистартабыз. Бу эшкә 550 берәмлек техника җәлеп ителә, – диде Казанның Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Альберт Ибраһимов. – Бозлавыкка каршы материал әзерләнде. 80 мең тонна тоз-ком кушылмасы һәм 32 мең тонна реагент бар.

Техникасы да, чималы да бар-барын, әмма эшче кулларга кытлык сизелә. «Аерым алганда, механизатор-йөртүчеләр җитми. Бу мәсьәләне хәл итәргә тырышабыз: килешүләр төзелә, акчаны арттырабыз», – дип ышандырды Альберт Ибраһимов.

Тагын бер яңалыклары: Казан эчендәге юлларда чисталыкны контрольдә тота торган навигация системасын видеокүзәтү белән җиһазларга җыеналар. Бу махсус техниканың йөрешен һәм вазгыятьне контрольдә тоту өчен мөһим.

САН

Татарстанда федераль әһәмияттәге 33 чакрым юл төзекләндерелгән.
Төбәк юлларында 79,4 чакрым автомобиль юлы, 1 юл үткәргеч һәм 6 күпер төзелгән һәм яңартылган, 488,9 чакрым юл һәм 5 күпер төзекләндерелгән.

Белеп тор

«Главтатдортранс»ның тәүлек буе эшли торган «кайнар элемтә» номеры: 8 (843) 291-91-91. Шушы номер буенча Татарстанның транспорт комплексы торышына бәйле мәгълүматны хәбәр итәргә мөмкин.
Транспортта QR-код куллануга бәйле сорауларны исә 8 (843) 291-90-12 номерына шалтыратып җиткерергә була.

Атна башыннан җәмәгать транспортында QR-код белән генә йөрергә мөмкин. Бу транспорт чараларының эшенә тәэсир иткәнме? Министр үзгәреш сизмәгән.

– Транспорт чараларын юлга чыгару гамәлдәге пассажирлар агымы нигезендә башкарылды. Рейслар саны кимемәде. Метро да элеккечә эшләде. QR-код тикшерү транспорт эшенә йогынты ясамады. Берничә очрак транспорт тоткарлану белән бәйле иде, – диде Фәрит Хәнифов.

Шулай да, чикләүләр кертелгәннән соң, Казандагы пассажирлар агымы – 25, ә Татарстанда 18 процентка кимегән. Башкача әйткәндә, транспортта Казан буенча 437 мең, Татарстан буенча 125 мең кешегә азрак йөргән.

– Баштарак авыр булыр инде. Аннан соң барысы да үз урынына кайтыр, җайланыр. Без тиз ияләшәчәкбез, – дип өметләнә министр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Озак яллар озаямы?

Кремльдә, пандемия сәбәпле, Яңа ел каникулын озайту ихтималы турында сорауга җавап бирелгән. Россия Президенты матбугат сәркатибе Дмитрий Песков белдергәнчә, ковидка каршы өстәмә чаралар кертү турында сөйләргә иртәрәк әле. Аның билгеләп үтүенчә, хәзер чирнең берникадәр сүлпәнәюе күзәтелә. Әмма яңа дулкыннарның китереп бәрү куркынычы да юк түгел. «Дөньяның барлык дәүләтләре бер проблема алдында калды – вакцинация һәм ревакцинациянең тиешле дәрәҗәсенә ирешелмәү бу», – дигән Песков.

Исегезгә төшерәбез: шушы араларда гына Яңа ел каникулының күпмегә сузылуы билгеле булды. Россия Хөкүмәте карары нигезендә, бәйрәм 31 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк. Халык 10 гыйнварда эшкә чыгачак.

Ясатмаска сәбәп түгел

«Медотвод» – прививка ясатмауга сәбәп түгел. Хроник чирләрдән интегүчеләрнең барысы да аеруча куркыныч янаган кешеләр төркеменә керә. Шуңа күрә, хроник чирнең көчәю чоры узуга, алар вакцинация узарга тиеш. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов шулай дип белдергән. Аның әйтүенчә, бүгенгә республикада 1,9 миллионнан артыграк кеше коронавирустан вакцинаның беренче уколын ясаткан. Шулай итеп, халыкның 60 проценты гына вакцинация узган әле. Ә күмәк иммунитет өчен бу санның 80 процент тәшкил итүе кирәк. Шул ук вакытта 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында прививка ясатучылар өлеше 50 процентка җиткән. «Болары да чир үзләренә аеруча зур куркыныч тудырган төркемгә керә. Шуңа күрә ковидны кисәтүнең төп ысулы вакцинация булырга тиеш», – дип искәрткән баш эпидемиолог.

Лопушов сүзләренә караганда, хәзерге вакытта балалар өчен вакцина һәм «Спутник V»ның борынга салына торганын эшләү тәгәлләнеп килә. «Яңа вакцинаны куллана башлагач, вирус хәтта өске сулыш юлларына да эләгә алмаячак», – дигән табиб. Сүз уңаеннан, республикада барлыгы 175 вакцинация пункты бар. Шуның икесе Казанда тәүлек әйләнәсе эшли.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көн кадагында

Утырт әле, абый!

Җәмәгать транспортына QR-кодсыз кереп булмаганын белмәгән кеше калдымы икән ул? Күпчелек яңа таләпкә әзер иде, моны аңлап кабул итте. Әмма төрле сәбәпләр аркасында кодлы була алмаган кешеләр дә бар бит. Әйтик, вакцинасының икенче дозасын алырга өлгермәгәннәр, прививка кадатырга мөмкинлеге булмаганнар...

Безнең халыкның акылына исең китәрлек: теләсә нинди җайсыз вазгыятьтән чыгу юлын эзли һәм таба ул. Әйтик, транспортта «кара шакмак»сыз йөреп булмагач, кешеләр социаль челтәрләрдә берләшеп, эшкә яисә кирәкле урынга илтеп куярлык машиналы юлдашлар эзли башлады. «Телеграм», «Ватсап»тагы чатларга кыска вакыт эчендә меңәрләгән кеше кушылды. Кемдер – бушка, кемдер акчага машинада урын бирергә әзер.

«Телеграм» каналдагы шундый бер аралашу чатына «ВТ» хәбәрчесе дә кушылды. Казан эчендә йөрү өчен булдырылган чатта төркемнең кагыйдәләре билгеләнгән: иң элек кеше үзенең кем икәнен – машина йөртүчеме яисә машина эзләүчеме – күрсәтергә тиеш. Аннан маршрут тәгаенләнә. Башка сорауларга җавапны исә булачак юлдаш белән шәхсән аралашу вакытында табарга мөмкин. Бушкамы, «рәхмәт» сүзенәме – анысын да бергәләп хәл итәсе.

Руслан исемле берәү көн дә иртәнге 8дән Казанның 10 нчы микрорайоны тирәсеннән «Бакчалар» тукталышына кадәр йөри икән. Кол Гали, Бертуган Касыймовлар, Зорге, Даурия урамнарын үтә. Машинасында дүрт урын буш, димәк, дүрт кешене шушы маршрут буенча утыртып йөри ала. Автобус бәясенә, ягъни 35 сумга, ди.

Павел исемлесе исә, Биектаудан Казанга кадәр машина эзлим, дип язган. Көн саен иртәнге 6да китәсе икән. Мондый хезмәт күрсәтүчегә 100 сум акча да түлим дип ышандыра.

Юлдаш эзләүчеләр арасында студент халкы да күп. Алар исә бер якка барасы кешеләргә, берләшеп, такси чакырырга яисә «попутчик»ка билгеле бер суммада акча түләргә тәкъдим итә.

Кайбер машина йөртүчеләр аеруча миһербанлы. Әйтик, Ләйсән Бәшәрова исемле бер кыз Гвардия урамыннан Пионерская урамына кадәр бер урын кирәк дип язган. Бер егет: «Борчылма, мин сиңа такси чакырам. Кешегә яхшылык эшләргә кирәк», – дигән. Гомумән, чатта күбрәк дустанә мөнәсәбәт рухы сизелә. Уртак бәла берләштерә шул.

Машина йөртүчеләргә «тимер ат»ларының арткы яисә эчке көзгеләренә махсус тасмалар элеп куярга киңәш ителде. Янәсе, юлда торган QR-кодсыз иптәш мондый тасманы күреп, бу кешенең аны утыртырга әзер булуын аңлаячак. Ә юлда басып торганнарга битлеген күрсәтергә кирәк, ди.

QR-кодсызлар берләшсә, QR-кодлылар таныша. Чынбарлык шундый хәзер: «кара шакмак»ны мөнәсәбәтләр төзегәндә дә сорыйлар. Бай, чибәр, фатирлы, машиналы, начар гадәтләре булмаган, фәлән төстәге күзле һәм... QR-кодлы. Икенче яртысын эзләүче кешеләр бу таләпнең үтәлүен дә тели хәзер. Танышу сайтларында да халык кодлы һәм кодсызларга бүленде.

Юрист ярдәмчесе булып эшләүче Алинә сөйләвенчә, QR-код системасы кертелгәнче егетләр белән очрашу урыны итеп йә кафе, йә кинотеатр, йә сәүдә үзәген сайлый торган булган. Вазгыять аларның да ишекләрен япты. Алинәнең QR-коды юк әлегә, чөнки вакцинаның икенче дозасын көтә. «Хәзер инде таныша башласаң, берәр кая чакырсалар да, баш тартырга туры килә. Моны сәбәп итеп «өеңә киләм» дип тәкъдим итүчеләр дә бар. Әлбәттә, андыйлар белән аралашуны шундук туктатам. Паркка, шугалакка чакыручылар бар. Бөтен җиргә дә код кирәкми бит әле», – ди ул.

Бер карасаң, мондый бүленеш адекват һәм адекват ук булмаганнарны билгеләргә ярдәм итәчәк. Танышу сайтларында кем генә утырмас бит!

Сүзгә-сүз

Александр БАСТРЫКИН, Россия Тикшерү комитеты рәисе:

Советлар чорындагы мәгариф системасын торгызырга кирәк. Ул дөньяда иң яхшысы иде, аның шулай икәнен барысы да таныды. Закон тәкъдимнәре шуңа юнәлтелсен иде. БДИны юкка чыгарырга кирәк, чөнки ул яшьләр өчен бер газапка әйләнде.

(Мәскәүдә узган фәнни-гамәли конференциядән)

ИҢ КИРӘКЛЕ ҺӨНӘР ИЯЛӘРЕ

Җәмгыять өчен иң кирәкле һөнәр нинди? «Работа.ру» хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россиядә яшәүчеләр укытучы, коткаручы һәм табиб һөнәрләрен җәмгыятькә иң күп файда китерә торган һөнәрләр дип атаган.

Табиблар	58%
Укытучылар	40%
Коткаручылар	28%
Янгын сүндерүчеләр	24%
Галимнәр	18%
Төзүчеләр	17%
Инженерлар	14%
Пешекчеләр	10%

Фаҗига булмый калган

Иминлек федераль хезмәте Казан шәһәре мәктәбенә кораллы һөҗүмне булдырмыйча калган. Нәтиҗәдә җинаятьне әзерләүгә җәлеп ителгән бер үсмер тоткарланган. Ул яши торган фатирда пневматик винтовка, эзләү системасына «Коралны сугышчан коралга ничек үзгәртергә?» дигән сораулар кертелгән элемтә чаралары, мәгариф оешмаларына кораллы һөҗүмнәр турында материаллар табылган. Сорау алганда, үсмер бу адымга аны Украинада яшәүче Овсюк Ярослав котыртуын әйткән. Алар үзара «Телеграм» аша аралашкан. Үсмергә карата «Ике һәм аннан күбрәк кешене үтерергә әзерләнү» статьясы буенча җинаять эше кузгатылган.

Тайгак юлда сак бул

Бозлавык аркасында Татарстан травмпунктларына мөрәҗәгать итүчеләр арткан. Республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәте китергән мәгълүматка ышансаң, Казанда гына да тайгак юлда имгәнүчеләр саны 133 кешегә җиткән. Шуларның 55ендә төрле дәрәҗәдәге сынулар ачыкланган.

Түбән Камада шундый ук мөрәҗәгать белән килүчеләр – 309 кеше.

– Хәзер бик куркыныч чор, һава торышына туры килгән аяк киеменә күчәргә өлгермәсәң, җәрәхәт алырга мөмкин, – ди Түбән Камадагы травмпункт мөдире Андрей Аркадьев. – Безнең тәҗрибәдән чыгып шуны әйтә алам: мөрәҗәгать итүчеләр күбесенчә күкрәк читлеге, аяк-кул, баш мие җәрәхәтләре белән килә. Мондый чор бигрәк тә 50 яшьтән өлкәнрәкләр өчен куркыныч.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТИГЕЗ УРЫННАН ТҮМГӘК ӘЗЛӘҮ

Бу юлларны язар алдыннан автор поляк радиосы сайтындагы баш мәкаләне русчага тәрҗемә итеп укыды. Ул язмада илнең премьер-министры Россия белән сугыш башлану ихтималының зур булуын әйтә һәм көнчыгыш күршесен газны сәясәт коралы итеп куллануда, Украина тирәсендә гаскәрләр туплауда гаепли. Мондый гаепләү Мәскәү тарафына бер Варшавадан гына түгел, океан артыннан ук яңгырый. Байден администрациясе көнбатыштагы аркадашларын русларның озакламый Украинага бәреп керәчәге турында кисәтә һәм әзерлек чаралары күрергә чакыра.

Әле кайчан гына бер түбә астында яшәгән өч дәүләт: Россия, Белоруссия, Украина бүген дөнья вакыйгаларының кайнарлыгын билгеләүче өчпочмакка әверелде. Әлбәттә, Россиянең көнбатыш чигендә сугыш башлану проблемалар юк. Әйтик, Белоруссия – Польша чигендәге качаклар мәсьәләсе – бик җиңел хәл ителерлек проблема. Берничә мең качакны Польша аша Германиягә уздыруы җибәрү – русча әйткәндә, «не стоит выеденного яйца» диган масштабтагы гына нәрсә ул. Үткән елларда Польшаның үзендә халык качакларга гуманитар коридор ачу, ягъни аларны Европага үткәреп җибәрү таләбе белән урамнарга чыкты, мәсәлән.

Икенче як тарафыннан да вазгыять тигез урында түмгәк эзләп табу һәм шуңа абынып егылырга теләүне хәтерләтә. Газ проблемасы да шулай ук. Көнбатыштагылар, үҗәтләнеп, Россиядән үзләренә газ китерәчәк «Төньяк агым»ны биклап тота, Мәскәү шундый кирелек белән газны Украина аша кудыруга каршы тора.

Америка, Англия һәм башка НАТО илләренең хәрби кораблары белән һава көчләре Кара диңгездә басымчаклык итә, Мәскәү аларның бу уенына бик теләп кушыла: төбәктә үзенең хәрби көчләрен туплый. Каршы торучы яклар бер-берсен ялган таратуда – дезинформациядә гаепли. Аңлашыла инде: ике як та әйбәт үк шыттыра һәм ике як та сугыш киеренкелеген саклау өчен тырыша. Глобаль капитализмның төп проблемаларының халыкларның игътибарын читкә юнәлтү өчен азапланалар. Төп проблема исә финанс түнтәрелешенең котылгысыз рәвештә якынаюында, халыкларның бүген үк инде бөлгенлек сазлыгында батуларында. Бөтен Көнбатышны иңләп килүче протест дулкынын туктату өчен, ахыр чиктә сугыш картасын уйнатырга мөмкиннәр. Бер төбәк сугышы мәсьәләне хәл итәр иде дип уйлый сәясәтчеләр. Проблемалар Европада икән, сугышны да әллә кайдагы Азиядә яисә Якын Көнчыгышта башлап файда юк бит инде. Якында булса гына авырттыра һәм сызландыра. Билгеле инде, авырткан җиргә кулны куясың, бөтен игътибарны шуңа юнәлтәсең. Шундый вазгыятьне ясалма рәвештә тудырырга телиләр. Сугыш башлана калса (аңа кемнең җиңүе әһәмиятле түгел, сугыш факты үзе мөһим дип уйланыла), кешеләр урамнарга чыгудан туктарлар, туктамасалар, вазгыятьтә сылтап, илләрдә хәрби хәл игълан итеп була. Андый вазгыятьтә теләсә нинди чара аклана.

Сугыш – финанс мафиясенең соңгы качу урыны һәм күптән сыналган ысул. Кытай үз проблемаларын Тайвань тирәсендә хәлне кискенләштереп чишәргә омтыла анә. Европалылар көнчыгыш чикне сайладылар. Безнең өчен бик куркыныч бу, әмма өметләник: эшләр куркытудан узмас, бәлки. Әле европалыларның кулында тагын бер уен картасы бар: утны һәм газны өзү. Суыкта ач утыра башласаң, урамга чыгып сикерәсе килмәс дип уйлыйлар. Шул карта белән фетнәне басып булмаса гына, сугыш фазасына күчәрләр, мөгаен.

Россиядә

АКЧА КАЧЫРЫП УЙНАГАНДА

Россия глобаль капитализмның бер состав өлеше буларак, андагы уен кагыйдәләреннән читтә кала алмый. Океан артыннан озакламый сугыш башланачагы турында яңгыраган хәбәрләр бездә финанс паникасы һәм сум түнтәрелеше булып кайтаваз бирә.

Россиянең финанс активлары белән алыш-биреш итеп уйнаган чит ил инвесторлары алардан ашыгып котылырга омтыла. Дүшәмбе көнне Мәскәү биржасында сум очсызланды. Россия компанияләренең акцияләре 2020 елның язындагы кебек, хәтта аннан да зуррак тизлектә бәяләрен югалтты, аларны күпләп сату – распродажа башланды. РТС индексы 5,55 процентка түбәнәйде. Иң зур 43 Россия компаниясе 15 миллиард доллар (сумга күчергәч, 1,1 триллион сум) акча югалтты. Мосбиржаның дүшәмбе югалтуы – 3,6 процент, үткән пәнҗешәмбедән дүшәмбегә кадәр түбәнәю – 8 процент. Карагыз: Америка разведкасының «руслар салкыннар башлану белән Украинага һөҗүм итәчәк» диган бер хәбәре күпме акчаның, куыклар шиеп, парга әйләнүенә китерде. Чын сугыш башланса, бөтен дөньядагы финанс түнтәрелешен аңлату өчен менә диган сылтау бит инде бу. Украина разведкасы башлыгы Кирилл Буданов та, янкилар сүзен кабатлап, Россия финанс системасын какшатуга үзеннән саллы өлеш кертте. Кремльдә сугыш башлау турындагы хәбәрләрне рәсми рәвештә кискен кире кагалар, әмма бу әлегә финанс паникасынын коткармый. Россия активларын саткан инвесторлар сумнарын валютага алыштыралар һәм акчаны бездән тыгалар. Сум түнтәрелеше шулай тәэмин ителә. Мәгълүмат сугышы ярдәмендә безнең кесәләрне чистарталар ягъни. Бу югалтуларны бәяләр үсеше нәтиҗәсендә халык җилкәсе күтәрәчәк бит инде.

Чит ил инвесторлары гына түгел, безнең үз олигархларыбыз да сумнарны долларга әйләндереп, оффшорга качыру темпларын көчәйткән. Салым федераль хезмәте акчаның Кипрга зур тизлектә шуушын белдерә. Былтырның 9 аенда гына да Россиянең юридик затлары 311,4 миллиард сумны дивидендлар рәвешендә Кипрга күчереп яшереп куйганнар. Менә федераль хөкүмәт әйтә бит инде: эшләүче пенсионерларның пенсиясен индексацияләргә акча юк, дип. Рәхим итегез: аңа җитәрлек акча оффшорга чыгып качкан. Дөрес, хөкүмәт акчасы түгел инде ул түгелеккә, әмма ил икътисадына ышанса, бюджетка да байтак тамар иде. Капиталның Кипрга качуы үткән ел белән чагыштырганда өч тапкыр тизләнгән. Ә болай, гомумән, тугыз айда Россияне ташлап качкан акча күләме 48 процентка үсеп, 59 миллиард долларга җиткән. Сумнарга әйләндерәсе дә килми, триллионнар турында бара сүз. Ә соңгы унике ай эчендә 70 миллиард долларның илдән китүен исәпкә алсаң, бөтенләй башлар әйләнә. Мондый хәл бары тик 2014 елда гына булган. Димәк, спекулянтлар һәм финансчылар инде вазгыятьне күптән сугыш хәле дип кабул итәләр.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында «Татнефть»нең Директорлар советы утырышын уздырды. Анда компаниянең ун айдагы бюджетын үтәү каралды, декабрь аена бюджеты расланды.

Директорлар советы иң элек «Татнефть» төркеменең 9 айдагы финанс-хуҗалык эшчәнлеге йомгакларын барлады. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, нефть чыгару – 5 процентка, шин җитештерү – 18, җылылык энергиясен җибәрү – 26, электр энергиясен эшләп чыгару 15 процентка арткан. Шулай ук нефть продуктларын эшләп чыгару һәм сату, нефть химиясе продукциясен һәм композит продукция җитештеру күләме арткан.

Утырышта, акционерларның чираттан тыш гомуми җыелышын җыеп, аларга 9 ай өчен дивидендларны раслау турында карар кабул итте. Дивидендны бер акция өчен 26 сум 50 тиен күләмендә түләү тәкъдим итeлде. Аның зур өлеше инде 6 ай йомгаклары буенча түләнгән. Җыелыш 29 декабрьдә узачак.

***

Президент «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыятенең Директорлар советы утырышын уздырды. Анда Рөстәм Миңнехановка кайбер инновацион проектлар турында мәгълүматлар җиткерделәр.

КФУның Бутлеров исемендәге химия институты профессоры Игорь Антипин республикада конструкцион термопласт җитештерүне җайга салырга тәкъдим итте. Полифениленсульфид – янмый торган бик нык материал. Аннан югары тизлектәге ракеталар һәм самолетлар өчен детальләр ясарга мөмкин. Шулай ук нефть-газ тармагында, автомобиль төзүдә һ.б. кулланырга була. «Стратегик чимал бу, аны мин йомгак белән чагыштыра алам. Җебеннән тартып, бөтен сәнәгатьне чыгара алачакбыз», – дип белдерде профессор. Рөстәм Миңнеханов әлеге технологияне нефтехимикларга өйрәнергә кирәклеген әйтте.

Утырышта шулай ук агрегатларның торышын «чыбыксыз» күзәтү, нефтьчеләр өчен компьютер тренажерлары проектлары, «СберРешения»нең Татарстан предприятиеләре белән хезмәттәшлекне җайга салу тәкъдиме каралды. Билгеле булганча, узган атнада Казанда компаниянең яңа офисы ачылды. Компания оешмаларга хезмәт хакын исәпләүгә, вакытлыча хезмәткәрләр сайлап алуга, шулай ук эш нәтиҗәсен яхшыртуга ярдәм итә. «Мин компания мөмкинлекләре белән танышым. Алар зур, шулай ук кече һәм урта бизнеска исәпләнгән. «СберРешения» белән хезмәттәшлекнең файда китерәсенә ышанам», – диде Президент.

Тәвә кошы да үрчи, чикләвеге дә үсә

Татарстан халкы тәвә кошы үрчетә, әстерхан чикләвеге агачы үстерә башлаган! Республикада узган авыл хуҗалыгында сан алу барышында шундый шаккаткыргыч нәтиҗәләр ясалган. Бу хакта Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында узган киңәшмәдә Статистика федераль дәүләт хезмәтенең Татарстан буенча территориаль органы (Татарстанстат) җитәкчесе Наталья Гатауллина хәбәр итте.

Аның сүзләренә караганда, хәзерге вакытта сан алу барышында тупланган мәгълүматлар эшкәртелә. Алар нигезендә бу тармактагы үзгәрешләргә күзәтү ясалачак, авыл хуҗалыгы өлкәсенә ярдәм чаралары билгеләнәчәк. Авыл хуҗалыгында сан алуда 598 авыл хуҗалыгы оешмасы, 2585 крестьян-фермер хуҗалыгы һәм шәхси эшмәкәр, 1383 бакчачылык җәмгыяте белән 420 мең шәхси ярдәмче хуҗалык катнашкан.

«Сан алуның биелгысы саналу объектлары санының да, участокларның гомуми мәйданының да артканлыгын күрсәтте. Кызганыч, авыл хуҗалыгында терлек санының кимүе расланды», – ди идарә җитәкчесе. Сан алуның якынча нәтиҗәләренә ышансаң, республикадагы җир участоклары белән йортларның 5 проценты ташландык хәлдә.

Статистика хезмәте белгечләре республика халкының нәрсәне һәм күпме ашавын да исәпләп чыгарган. Баксаң, Татарстан халкы шикәр, ипи һәм кондитер ризыкларын Идел буенең башка төбәкләрендә яшәүчеләр белән чагыштырганда азрак ашый икән. Сөт һәм сөт ризыкларын, бәрәңге ашау буенча без әлеге төбәкләр арасында – икенче, яшелчә, җиләк-җимеш ярату буенча өченче урында икән.

«Татарстан сөт һәм сөт ризыкларына булган ихтыяҗны тулысынча каплап бара. 2020 ел нәтиҗәләре буенча, бу күрсәткеч 122 процентны тәшкил итә», – ди Татарстанстат идарәсе башлыгы.

Узган ел республикада ит һәм ит продуктлары белән тәэмин итү дә 111,5 процентка җиткән. 2019 елда бу күрсәткеч 108,5 процент тәшкил иткән булган. Шул ук вакытта үзебездә җитештерелгәнне читкә чыгарып сату күрсәткече дә 0,6 процентка арткән.

ӨЛКӘННӘР БӘЙРӘМ КӨТӘ

veteranytatarstan.ru

Фестиваль

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк оешмасы рәисе Хәбир Иштиряков әнә шулай ди. Кичә Татарстан Дәүләт Советында һәвәскәр башкаручыларның «Балкыш» фестивале хакында сөйләштеләр. Коронавирус тормышыбызга чикләүләр кертсә дә, күпне күргән, тормышта чыныгу алган өлкәннәр бирешми. Алар катлаулы вазгыятьтә ничек тә үз күңелләрен күреп яшәргә өйрәнә. Вирус үзенекен эшләде, сәхнәдән төшмәгән, мәдәният йортларыннан кайтып кермәгән әби-бабайлар өйдә утырырга да өйрәнде. Әмма аларны ул да туктатмады, өлкәннәр читтән торып җырлыйлар да, биилэр дә, иҗат та итәләр хәзер.

– Онлайн форматка күчкәч тә, «Ватсап»та үз төркемебезне булдырып, шунда аралаштык. Бирелгән сөйләшүләр бәйрәмгә әйләнде. Интернет аша аралашырга, бер-беребезнең иҗат эшләрен күрергә дә өйрәндек. Кемдер җырлады, кемдер матур итеп шигырь сөйләде. Кул эше осталары исә үз һөнәрен күрсәтте, – ди Хәбир Иштиряков. – Ветераннар иҗатының чиге юк аның. «Балкыш» («Сияние») ветераннары арасыннан үзешчән башкаручылар фестивале – моңа ачык мисал. Кирәкле шартлар тудырылса, өлкәннәр талантларын күрсәтә ала. Без шуңа инандык. Колхозда бил бөккән, сыер сауган, трактор йөрткән, мәктәпләрдә балаларга белем биргән кешеләр сәхнәне моңга күмә. Аларның һәр чыгышын сулыш алмый тыңлыйсың. Фестиваль күп талантларны ачты.

Әлеге фестивальнең оештыру комитетын Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкли.

– Өлкәннәргә чиксез рәхмәт. Катлаулы ел булуга карамастан, сез бу бәйрәмне узудыру җаен табасыз. 2012 елда башланган беренче фестивальдә 3,5 мең кеше катнашса, 2020 елда бу чарада 25 меңнән артык кеше чыгыш ясады. Узган ел карантин игълан ителгәч, фестивальнең икенче этабы онлайн форматта узды. 46 сәгатьлек видеоматериал җыелган. Әлеге фестивальнең гала-концертын «ВКонтакте» социаль челтәрендә 47 меңнән артык кеше караган. Фестиваль халыкларны да берләштерә. Бирелде бит күпме миллəт вәкиле чыгыш ясый. Чуашы да, удмурты да, татары да, урысы да бер сәхнәдә җырлый-бии, күңел ача, – ди Фәрит Мөхәммәтшин. – Бүген без киләсе елда узачак фестивальнең зона турларына вакытын билгелибез. Әлеге эшне башкарып чыгу җиңел түгел. Шуңа да фестивальгә өлеше кергән һәр кешене билгеләп үтәргә кирәк. Пандемия шартларында аеруча күп хезмәт таләп ителә.

Хәбир Иштиряков та шул фикердә. Онлайн форматта үткәрү күп хезмәт таләп итсә дә, оештыручылар аның уңай якларын да әйтә. Узган елларда җырларның күбесе ябык биналарда түгел, табигать кочагына чыгып яздырылган. Хәбир Иштиряков: «Һәр эшне коронавирус вазгыятенә карап башкарачакбыз», – ди.

– Киләсе елда оешмабызга 35 ел була. «Балкыш» фестивале бу вакыйгага багышланыр дип ниятләдек. 2020 елда пандемия аркасында фестивальдә өч район катнашмый калган иде. Быел алар җиң сызганып тотынып инде, – ди ул. – Без иң элек Казан, Чаллы, Арча, Алексеевск, Буа, Әлмәт, Кукмарада зона турлары оештырабыз. Аннан сайлап алынган талантлар октябрьдә, Өлкәннәр декадасында узасы гала-концертта чыгыш ясачак.

Катнашучыларны җиде зонага бүлеп тыңлаунлы Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова да хуплады.

Өлкәннәр «Балкыш» фестивален зарыгып көтә. Тукай районының Яңа Буләк авылында яшәүче Рәшидә Мирсәетовага – 94 яшь, фестивальдә катнашырга әзерләнә башлаган инде.

– Рәшидә апага киләсе елның гыйнварында 95 яшь тула. Беренче тапкыр 2017 елда Казан сәхнәсендә чыгыш ясаган иде. Ул чакта аны куркып кына юлга алып чыгып киттек. Янәсе, яше олы. Бик әйбәт барып кайттык. Рәшидә апаны сәхнә һәм җыр яшәтә. Тагын катнашам дип тора әле. Кем белгән, бәлки, тагын Казанга бару насыйп булып куяр, – ди Яңа Буләк авылы мәдәният йорты директоры Дилбәр Гыймазетдинова. – Бу фестивальне оештыручыларга чиксез рәхмәт. Алар өлкәннәрнең гомерен озынайта, яшьлегенә алып кайта. Безнең халык, ничә яшьтә булса да, җырсыз-моңсыз яши алмый шул ул!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯЛГЫШМАС ӨЧЕН ТЫҢЛАРГА КИРӘК

Сорауларга – җавап

Татарстанда киләсе елга алты министрлыкның өстенлекле юнәлешләрен билгеләү буенча тавыш бирү дәвам итә. Болар – Сәламәтлек саклау, Мәдәният, Мәгариф һәм фән, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Спорт, Яшьләр эшләре министрлыклары. Бүген 24 мең кеше үз тавышын биргән инде. Сораштыруда 7 декабрьгә кадәр катнашырга мөмкин.

tatarstan.ru

– Мондый тавыш бирү республикада дүртенче тапкыр оештырыла. Башта анда дүрт министрлык катнашса, 2019 елда Яшьләр һәм Спорт министрлыклары да кушылды. Быел проектка старт 13 сентябрьдә бирелде. Беренче этапта белгечләр бурычларны, максатларны билгеләде. Быелгы үзенчәлек – белгечләрнең саны арту. Әйтик, республика Мәдәният министрлыгында аларның саны 80 процентка яңартылды. Тавыш бирүдә катнашучылар саны елдан-ел арта бара, – диде Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева матбугат очрашуында.

Республика Сәламәтлек саклау министрлыгыннан тавыш бирүгә паллиатив ярдәмнең күләмен, авыл халкына медицина ярдәме алу мөмкинлекләрен, кан бирүчеләр санын, медицина оешмаларында органнары күчерү буенча тәҗрибәне арттыруга бәйле сораулар чыгарылган. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет белгече Чыңгыз Мәхмүтов әйтүенчә, министрлык халык белән аралашуның төрле формаларын булдырган.

– Табиблар халыкның нәрсә борчыганын белеп торырга тиеш. Бездә уку йортларында, сәламәтлек саклау тармагында эшләүче хөрмәткә лаек булган белгечләр бар. Алар төрле сораулар буенча фикер алышып, тавыш бирүгә чыгара. Халык та үзен борчыган сорауларны җиткерә. Узган ел ковидтан соң халыкны тернәкләндерүгә караган сорауларны тавыш бирүгә керттеләр. Теләсә нинди карар кабул итәргә була, тик аларның үтәлүе мөһим. Халыкны яман шеш, кан тамырлары авыруларына бәйле сораулар борчый. Төрле тикшеренү, УЗИга язылу мөмкинлекләре дә кызыксындыра. Шулай ук тар профильле белгечләрнең булуы мөһим, – диде Чыңгыз Мәхмүтов.

Журналистлар табибларның УЗИ, компьютер томографияләрен бушлай үтәр өчен юллама бирергә ашыкмавын да җиткерде. Түләүлегә урын бар, бушлай үтәргә юк булып чыга.

– УЗИ, компьютер томографияләре буенча нормативлар бар. Хәзер халык интернеттан укып, үзләренә диагноз куя. УЗИга барырга кирәк, ди. Табиблар бит кемне җибәрәсен белә. Мондый очракларны ачыкламыйча аның кына берни әйтеп булмый. «Кайнар линия», «Халык контроле»нә килгән сорауларны урыннарга барып тикшерәбез. Әлеге сорауларны актив күтәреп, тавыш бирүгә дә кертеп була, – диде Чыңгыз Мәхмүтов.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет рәисе Асия Тимирясова үз чыгышында узган еллардагы өстенлекле юнәлешләр нәтиҗәләре белән таныштырды. Хәзерге вакытта 15 юнәлеш буенча тавыш бирү бара.

– Өч ел элек мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар булдыру буенча вазгыять тотрыкланды. 2020–2021 елларда гына республикада 44 яңа бакча төзелде. Илдә моның кадәр бакча төзеган бер генә төбәк тә юк. Бу – 10 мең өстәмә урын диган сүз. Шул исәптән, 4 меңе – 1,5–3 яшькә кадәрге сабыйлар өчен. Ресурс үзәкләре саны артып, 43кә җитте. Урта һөнәри уку йортлары яңартылу да – күңелле күренеш. Мәктәпләрдә башлангыч сыйныф укучылары кайнар ризык белән тәэмин ителде. Быел исә сораштыруда беренче тапкыр сәламәтлеге чикле булган балаларны укытуда шартлар тудыру, фәнни кадрларны яңарту, әти-әниләр белән тәрбия эшен арттыру, мәктәпләрдә иминлек мәсьәләләренә урын бирелде, – диде Асия Тимирясова.

Иҗтимагый палатаның социаль мәсьәләләр һәм хәйриячелек буенча комиссия җитәкчесе Маргарита Максимова белдергәнчә, сораштыруда сәламәтлеге чикләнгән балаларны һөнәргә өйрәтү, инвалидларны эшкә урнаштыру, халыкны эшле итү мәсьәләләре урын алган.

– Халык фикер алышуда катнашканда гына министрлык үз үсешен дөрес билгели ала. Җәмгыятьнеке кайчан ничек эшләргә кирәк икәнен дә күрсәтә. Тәнкыйди фикерләр дә була. Актив катнашучылар максатларны ачыкларга булыша. Алардан башка проблемаларны хәл итеп булмый, – диде ул.

Министрлык бурычлары турында http://publictasks.tatarstan.ru порталында, шулай ук министрлыклар сайтларында танышырга мөмкин. Анда 2021 елга министрлыкларның бурычларын үтәү нәтиҗәләре дә урын алган. Иң күп тавыш җыйган тәкъдимнәр декабрь аенда иҗтимагый советлар утырышларында каралачак. Нәтиҗәдә һәр министрлык өчен киләсе елга 5–7 өстенлекле максат билгеләначәк. Тавыш бирү белән берәттән, үз тәкъдимнәреңне дә калдырырга мөмкин.

Сәрия МИФТАХОВА

ГАҖӘЕП РЕКОРД

50 ЕЛДАН АРТЫК ҖИТӘКЧЕ ВАЗЫЙФАЛАРЫНДА ЭШЛӘГӘН САЛИХ БАТЫЕВНЫҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ

Шәхес

1960 елны Салих Батыевның утызынчы елларда Бакалы (Башкортстан АССР) райкомында пропагандист буларак башланган партия эшчәнлегенә нокта куела. Тик бу тукталып калу дигән сүз түгел, аны алда тагын да катлаулырак эшләр көтә.

Салих Гыйлемхановичка икенче көнне үк Татарстан АССР Югары Советы Президиумы рәисе, РСФСР Югары Советы Президиумы рәисе урынбасары вазыйфалары йөкләнә. Бу эшкә керешкәнче, аңа күп кенә документларын яңадан ясатырга туры килә. Монысы милләтен татар дип алыштыруга бәйле. Әлеге көнгә кадәр ул башкорт булып йөргән. Шул рәвешле аның, дәүләт эшлеклесе буларак, 23 елга сузылган эшчәнлеге башлана. 1983 елны отставкага китә. «Сигез ел Татарстан АССР Министрлар Советы рәисе урынбасары булып, тугыз ел партия өлкә комитеты секретаре булып эшләгәнен дә исәпкә алсаң, Батыев республика тарихында югары җитәкче вазыйфаларында һәм партия-дәүләт структураларында иң озак эшләүче кеше буларак абсолют рекорд куя. Бу – 50 елдан артык дигән сүз», – дип яза күренекле тарихчы Булат Солтанбәков аның турында.

Комсомол – кояшлы яшьлек...

Салих Батыев 1911 елның 24 декабрендә Уфа губернасының Бәләбәй өязендәге (хәзерге Чакмагыш районы) Яңа Дөмәй авылында гади крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Кечкенәдән башлы, актив булуы белән аерылып тора. Мәктәптә укый. Әтисенә хуҗалык эшләрендә булыша. Колхозда эшли. 16 яшендә авылда комсомол ячейкасы оештыра. Үзешчән сәнгатьтә катнаша, яңа власть өчен көрәшкә өнди.

Актив егетне тиз күреп алалар һәм Бакалы райкомына пропагандист итеп эшкә чакыралар. Бер үк вакытта ул Казан финанс-икътисад институтында укый. 1933 елда Акташ районы МТСына сәяси бүлек башлыгының комсомол эше буенча урынбасары итеп куялар. Аннан Арча ВЛКСМ райкомы секретаре, Татарстан өлкә комитеты бүлек мөдире вазыйфаларын башкара.

Кулга алынудан котылып кала

Эш сөючән, дәрте кайнап торган егетнең партия һәм сәясәт өлкәсендәге абруе көнләп түгел, сәгатьләп үсә. Әмма шуңа да карамастан, 1937 елның 2 августында Татарстан ВЛКСМ өлкә комитетының карары белән ул «халык дошманнары белән элемтәдә тору сәбәпле» эшеннән азат ителә. Аптырап калмый: фельдшер-акушерлык мәктәбенә СССР халыклары тарихы укытучысы булып урнаша. 1937 елның 17 декабрендә Казанның Молотов партия райкомы бюросы аны «халык дошманы Саттар Еникеев белән элемтәдә булганы өчен» партия сафларыннан чыгару турында карар кабул итә. Саттар Мөхәммәтҗанович Батыевның дусты һәм хатыны ягыннан туганы була. Татарстан АССРда мәгариф халык комиссары урынбасары, «Кызыл Татарстан» газетасының мөхәррире булып эшли.

Салих Батыев могҗиза белән генә кулга алынмый кала. Бу – НКВД аппаратында Николай Ежов урынына Лаврентий Берия килгән чак. Шул сәбәпле төрле аңлашылмаучанлыклар килеп чыгып, кайберәүләр исемлектән төшеп тә кала, күрәсең. Батыев хәтта үзен яңадан партия сафларына кабул итүләренә дә ирешә.

Институттан партия эшенә чакырылу сәбәпле, югары уку йортын тәмамлый алмаса да, 1939–1941 елларда Батыев өлкә комитетында лектор булып эшли, бер үк вакытта Казан химия-технология институтында укыта, соңрак аны ТАССР Җир эшләре комиссариаты сәяси бүлекчәсе башлыгы урынбасары итеп билгелиләр. 1943–1947 елларда ул – ТАССР Министрлар Советы рәисе урынбасары. Яшь һәм перспективалы җитәкче буларак, аны Мәскәүгә – Югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Өч ел укыганнан соң ул башкалада эшли.

tatmuseum.ru

Салих Батыев (уртада) ил җитәкчеләре белән

Муса Җәлилнең исемен аклый

Мәскәүдә кат-кат тикшерү үткәннән соң, Батыевны җаваплы партия эшләрен алып барырга Татарстанга юллыйлар. Ул – 1951–1960 елларда Татарстан КПСС өлкә комитеты секретаре. Бер үк вакытта КПСС Үзәк Комитеты партия мәктәбенең Казандагы филиалында партия һәм совет төзелеше кафедрасын җитәкли.

1956 елны Салих Гыйлемханович Татарстан, Удмуртия, Мари һәм Чуашстан республикаларында сәяси тоткыннарны аклау буенча СССР Югары Советы комиссиясе рәисе булып сайлана. Аның ярдәме белән бу елларда күп кенә тоткыннар азат ителә. Шул көннәргә кадәр хыянәтче булып исәпләнгән шагыйрь Муса Җәлилнең намуслы исемен кайтаруда зур роль уйный. Салих Батыев һәм ТАССР өлкә комитетының беренче секретаре Зиннәт Моратов тырышлыгы белән шагыйрь тулысынча аклана һәм аңа үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Шулай ук төрмәдә язылган «Моабит дәфтәре» җыентыгы өчен Ленин премиясе тапшырыла.

Гаепсезләрне ирекккә чыгара

Батыевның кызы Эльвира Салиховна истәлекләрендә болай дип яза: «Әтием күп кешеләрне аклар өчен генә тырышып калмады, кайберләренә тормышта үз урыннарын да табарга ярдәм итте: эшкә урнаштырды, торак эзләште. Аны аңларга да була: үзе дә чак кына репрессиягә эләкми калган бит». Тарихчы Булат Солтанбәков исә: «Шул ук вакытта күп кенә тарихи вакыйгаларга, шәхесләргә тиешле бәя бирергә Батыев әзер булмый. Мәсәлән, ул бик кинаяле итеп: «Солтангалиевне партиягә Троцкий һәм Бухарин белән бер вакытта гына кабул итәрләр инде», – дип әйтә. Мондый чагыштыру белән ул аклану эшенең мөмкин түгеллеген ассызыклый. Әмма ничек кенә булмасын, «андый урын»нардан кайтканнар Батыевның кеше ихтыяҗларына игътибарлы булуы турында сөйлиләр».

Тарихчылар Батыевның тагын бер кешелекле ягын билгеләп үтәләр. Ул Казан психиатрия хастаханәсендә мәҗбүри дәвалануга мохтаҗ булмаган сәяси тоткыннар барлыгы турында КПСС Үзәк Комитетына мөрәҗәгать яза. Нәтиҗәдә Мәскәүдән комиссия килә, тикшерүләрдән соң күп кенә тоткыннар азат ителә.

Таләпчән, әмма гадел

Салих Батыевны ил җитәкчеләре дә хөрмәт итә. Ул Татарстанның икътисадын, мәдәниятен, сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү өчен күп көч куя. Аны замандашлары, таләпчән, әмма гадел, дип бәялиләр. Югыйсә, тарихчылар әйтүенчә, партия өлкә комитеты өчен дә бик «җайсыз» кеше булып санала ул. Бигрәк тә закон саклау эшләренә кагылганда, Салих Гыйлемханович үз фикерләрен турыдан-туры бәреп әйтә торган була. Әмма ничек кенә булмасын, аның белән киңәш-табыш итәләр, тәҗрибәсенә, ярдәменә таяналар.

Салих Батыев Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында саллы эз калдыра. «Аның тормыш принциплары бик гади: вөҗдан кушканча яшәргә, армый-талмый хезмәт итәргә, һәр көнне тирә-юньдәгеләр өчен файдалы итеп үткәрергә», – ди аның хакында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Күпьеллык лаеклы хезмәте өчен Батыев Октябрь революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, Почет билгесе, медальләр белән бүләкләнә.

Салих Гыйлемхан улы Батыев 1985 елның 7 декабрендә Казанда вафат була. Яңа Татар бистәсенең Татар зиратында җирләнә.

2006 елны Батыев 1960–1985 елларда яшәгән йортка истәлек тактасы куела. 2011 елда Казан шәһәренең Идел буе районындагы бер урамга аның исеме бирелә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЮККА ТҮГЕЛ БУ

Мин Ринат абый үрнәгендә Казанда «Оргсинтез» берләшмәсенә эшкә урнаштым һәм шунда 34 еллык хезмәт стажы тупладым. Бик тату, бердәм коллектив иде ул. Шулай да күңелемдә бераз төер дә калды. Анысы хезмәтемнең соңгы еллары белән бәйле.

1994 елда мин намазга бастым һәм мөселманча киенеп йөри башладым. Заводта моңарчы андый хәл күзәтелмәде булса кирәк, шунлыктандыр инде мине аңламаучылар да табылды һәм: «Болай булса, сине эштән куачаклар, менә күреп торырсың», – диючеләр дә булды. Эш вакытында бүленеп, намаз укуымны өнәп бетермәүчеләр да бар иде. Дамира дигән исемемне Газизәгә үзгәртүемне дә гаеп иттеләр, улым белән кызымның исемнәрен Нурислам белән Исламиягә алыштыруым да кайберәүләргә ошап җитмәде. Әйе, монда нәкъ менә кайберәүләрнең, бер-бер хәл түгелме икән, дип эче пошты.

Үзгәрешләр дин әһелләренең, өйдәгеләрнең хәерфатыйхасы, ризалыгы белән башкарылды югыйсә.

Хәбәрләр җитәкчебез Наил абый Йосыповка да барып җиткән иде, көннәрдән бер көнне ул үзенә әңгәмәгә чакырды. Бу хакта бухгалтериядә эшләүче хезмәттәшләремә дә белдергәч: «Юкка түгел бу», – диделәр, минем исә исем китмәде, дин юлына басканмын икән, шул юлдан тайпылмаячагым, мөселманча яшәү рәвешеннән ваз кичмәячәгем, үгет-нәсихәтләргә бирелмәячәгем ачыктан-ачык иде инде.

Директор бүлмәсенең ишеген ачуга ук көр тавыш белән: «Бисмилләһир-рахманир-рахим, – дидем дә, – Әссәламегаләйкем», – дип сәламләдем. «Бәрәкалла, – дип урыныннан күтәрелде директор. – Бу бүлмәгә бисмилла әйтеп керүче юк иде әле. Бу хәл берүк дәвамлы була күрсен».

Директорыбыз белән бик җылы әңгәмә булды. Ул минем уй-фикерләремне, тормышка, янәшә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәтемне белү өчен чакырган икән. Саф татарча аралаштык, ул мине кабул итү бүлмәсенә кадәр озата да чыкты. Шуннан соң миңа бер генә кырын караучы да, мыскыллы караш ташлаучы да булмады, эштә дә үз вазыйфамда калдым. Дин юлына басуымны туганнарым Ринат абый, Харис абый да бик хупладылар. Хәзер инде мин изге юлда булуыма шатланып бетә алмыйм. Берничә тапкыр хаҗ сәфәренә дә барып кайттым. Бу изге гамәлдә дә Харис абыем нык булышлык күрсәтте. Әнкәй, Аллага шөкер, озын гомерле булды, 22 ел бездә яшәде. Балаларны тәрбияләүдә аның өлеше зур булды, мин инде өлкән яшьтә, дип тормады, йорт эшләренә дә булышты.

Гомер – агымсу, дип юкка гына әйтми халык. Бик тиз үтә, әмма хәере белән, изге гамәлләр белән үтсен.

Газизә ӘПСӘЛӘМОВА

Кәшкәләү табибы

Элек-электән авылларда фельдшерлар абруйлы медицина хезмәткәре булып саналды, нәкъ менә алар барлык авыруларга да беренче ярдәмне бирергә тырышты һәм хәзер дә шулай. Барлык көчен, акылын шушы вазыйфага багышлап, сайлаган һөнәренә тугры калган олуг затлар яши безнең арабызда. Шундыйларның берсе – Әлфинә Хәкимова Башкортстанның Борай районы Кәшкәләү авылында гомер итә. Быел аңа 80 яшь тулды.

Балачактан ук медицина хезмәткәре булырга хыяллана ул. Урта белем алып, башкалар нинди һөнәр сайларга баш ватканда, һич икеләнмичә документларын Бөре медицина училищесының фельдшер-акушерлар әзерләү бүлегенә тапшыра. Укуын тәмамлагач, аны Кәшкәләү авылындагы бала тудыру йортына бүлек мөдире итеп җибәрәләр.

«Бүгенгедәй хәтеремдә, – дип сөйләргә ярата әни, яшь чакларын искә төшереп, – караңгы көзләрнең берсендә, эшләр беткәч, ятып йокладык, ишек бикләнмичә калган. Күрше авылның бер кешесе өйгә килеп кергән, уянучы юк, арыганбыздыр инде, куллары белән эзли-эзли, без яткан караватка килеп юрганны ача башлаган, әни куркуыннан идәнгә егылып төшкән». Кызык хәлләр булды инде, куркынычлары да, шатлыклылары да. Ике авыл арасында машинага мотоцикл бәрелгән. Ашыгыч ярдәм чакырырга ул вакытта кәрәзле телефоннар юк бит инде. Иң якыны – безнең өй. Яшь егетнең гомерен саклап кала алмаган. Бик үкенгән. Шуннан соң үзенә, бер балам да табиб булмаячак, дигән сүз биргән. Чыны да шулай: биш баланың берсе дә табиб булмады, кайберләренең теләге көчле булса да. Ләкин тормыш барыбер үзенекен итә, кызының кызы бүген – кызыл дипломлы табибә.

Әниебез ярты гасыр, ару-талуны белмичә, шәхси кичерешләрен һәм борчуларын күрсәтмичә, авылдашларының сәламәтлеген кайгыртты. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, яңгырда да, буранда да урында булырга һәм авыруга ярдәмгә килергә әзер торды. Югыйсә йорт-җирне дә, гаиләне дә карап торырга кирәк. Бу яктан әтиебез аңа беренче ярдәмче булды һәм бүген дә шулай. Алар бик матур тормыш корып, 60 елга якын гомер итәләр. Үзләренең дүрт һәм якын туганнарының бер баласын тәрбиягә алып, зур тормыш юлына бастырдылар. Инде хәзер үзләре дә әти-әни, аларның балаларына кадерле дәү әни һәм дәү әти булып яшиләр.

Хезмәте барның хөрмәте бар: халыкка медицина ярдәме күрсәтүдә тырышып үрнәкле эшләгәне өчен әниебез күп тапкыр мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр, рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. Ул – хезмәт ветераны, мактаулы донор. Ә иң зурысы, әлбәттә, халык рәхмәте. Кәшкәләү, Давытавыл, Ишмәмәт, Бакалы, Иске Каратыш, Яңа Каратыш авылларында ул – иң хөрмәтле кендек әбисе.

Алия ХӘСӘНОВА, Казанда яшәүче кызы

БАБАЙ КИТАПЛАРЫ

Күбебезгә – 5–6 гына яшь. Бөек Ватан сугышының кызган чагы. Әнинең әтисе Шаһвәли бабайны шул яшьтән хәтердә калдырдым. Кая гына барса да, дини генә түгел, төрле фәнни, дөньяви китаплар сатып алып укыган, нәтиҗәдә профессорлар белән дә аяк терәп гапләшерлек-бәхәсләшерлек гыйлем иясе иде. Бабай дөньяның әчесен-төчесен күп татыган, сабый чагыннан әти-әнисеннән ятим калган, бабасы тәрбиясендә үсеп, авылда дөньяви фәннәрне, шул исәптән рус телен дә өйрәткән җәдит мәдрәсәсен тәмамлаган, 17 яшеннән авылдан чыгып китеп, үткән гасырның башында ук Россиянең иңен-буен айкап, Бакуда нефть промыселында эшләгән. Аннары Кавказ губернаторы Лубенцовның пресс-секретаре булган, соңыннан Якутиянең Лена алтын приискаларында эшләп, 1921 елны восстаниедә катнашкан өчен төрмәдә дә утырып чыккан. Туган ягы Мунчәлигә кайтып, авылның чибәр кызы Һаҗәргә өйләнеп, 12 кыз-малай тәрбияләп үстергән (минем яшьләрдәге кече улы Нурмөхәммәт – бүгенге тел-әдәбият галиме, академик).

Мунчәли халкы аны үзенең рухи атасы, тәрбиячесе, имамы дип таный иде. Кышкы озын кичләрдә бүгенге кайбер мәктәпнең бөтен бер классындагы хәтле 9–10 балага Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанын күңелдән, көйләп сөйләгәне әле дә хәтердә. Абыйларының 11 яшьлек Йосыфны коега ташлау күренешен сурәтләгәндә, барыбыз да, күз яшьләребезне тыя алмый, үксеп елый идек. Аннары башка кичләрдә бөек татар полководецы яугире Чыңгыз хан, аның улы – Алтын Урда дәүләтенә нигез салган Җучи, аннары Русьне дә яулап, бик зур Алтын Урда дәүләте төзеп, 1240 елгы Европага походы вакытында Батый ханның бу континентның дистәләгән ил-дәүләтен үтеп чыгып, татарларның дәһшәтле көч-куәтен күрсәтеп, шәп сабак биреп, шәһри Болгарга кайтуы турында бабай, бу вакытларны үз күзе белән күргәндәй, бик кызык итеп сөйли иде. Соңыннан, без үскәч, авылыбызның Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис белем алган 7 еллык мәктәбенә килеп (башында – чиккән түбәтәй, өстендә – бик килешле камзул, аягында – читек), безгә, җиденче класста укучыларга, тарихтан һәм әдәбияттан лекция-дәресләр үткәрүе дә бүгенгедәй хәтердә. Я, әйтегез әле, кайсыгыз үзенең шундый уникаль бабасы белән мактана, горурлана ала? Ә халкыбызда Габдрәхим Утыз-Имәни, Габделҗаббар Кандалый һ.б. кебек әнә шундый укымышлы өлкәннәр күп булган. Хәтта соңыннан, инде XX гасыр башында, бер мәкаләсендә Ленин, грамоталылык – аң-белем дәрәҗәсе буенча татарлар Россиядә беренче урында булган икән, дип гаҗәпләнә!

Бабай турында, бер әйтемдәге кебек, җитмеш төрле һөнәргә ия дип әйтергә була иде. Ул, бик шәп умартачы буларак, 30–40 умарта оясы тота иде. Шуңа күрә Казанда, Ульяндa, тирә-як район базарларында бал белән уңышлы сәүдә итте. Шуңа күрәдер дә аның ишле гаиләсендә азык-төлек һәрвакыт күп булды. Шуны да өстим әле: боларны бүген мин – бабайның 85 яшьлек оныгы язмаса, кем язар икән?!

Сүз башым – Шүрәле дигәндәй, бабайның һич хәтердән чыкмас тагын бер гадәте турында аерым әйтәсем килә. Ул, кая гына, нинди генә шәһәргә барса да, бер кочак балалар китаплары күтәреп кайтып, безгә өләшә иде. Шулар арасында Мәҗит Гафуриның «Балалар күңеле» исемле бармак калынлыгындагы китабын бүген дә хәтерлим. Без аны, урамга алып чыгып, күрше малай-кызлары белән дә укый-укый тетеп бетердек. Мин бүген дә Мәҗит Гафурины Тукайдан соң икенче урындагы бөек шагыйребез дип саныйм. Аның олыларга адресланган күп шигырьләрен, шул исәптән «Татар егетенә» шигырен әсәрләнеп укыганым бар. Башкортлар аны үзләренең шагыйре диләр. Ике халыкның яраткан әдибе булу начар түгел инде анысы. Шулай да нишләп ул үзенең атаклы әсәрен «Башкорт егетенә» дип атамаган соң? Ни дисәң дә, Җилем Каран дигән татар авылында туып үскән, әсәрләрендә дә үзен «татар» дип атаган чын татар кешесе бит инде ул.

Мәҗит Гафуриның балаларга атап язган кайбер шигырьләре бүген дә истә. Мәсәлән, «Зәйнәп» әсәрендә бер кызның бик начар гадәте турында:

«Бигрәк шапшак безнең Зәйнәп –
Йөри лач-лоч сагыз чәйнәп», – дигән юллары.

Тагын бер нәрсә борчый бу уңайдан. Бүген нишләптер тәнкыйтьчеләребез дә, әдәбият галимнәребез дә мәшһүр әдибебез турында бөтенләй язмыйлар. Тукай да яраткан олы әдибебезне онытырга хакыбыз юк. Ул бит бүген дә үзенең әсәрләре белән халкыбызга хезмәт итә.

Фарук НӘФИЕВ.
Тәтеш

Белдерү

Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границ земельного участка

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом Саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2-5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:270101:587, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, пер. Иман, 10, проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.
Заказчиком кадастровых работ является Наумихин Артем Александрович (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 89030618183).
Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 24 декабря 2021 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.
С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.
Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, д. 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63 с 24.11.2021 г. по 24.12.2021 г.
Смежный земельный участок, с правообладателями которого требуется согласовать местоположение границ земельных участков с кадастровым номером:
16:50:270101:588, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, п ИЖС «Союз офицеров и прапорщиков запаса», участок 32–13.
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

«БЕЗ МОНДА БАРЫСЫН ДА КҮРӘБЕЗ»

КАЗАНДА ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ КӨЧЛЕ ЕГЕТЛӘРЕН АЧЫКЛАДЫЛАР

Алексей Абрамов

Илназ Миңмуллин

Ислам Фәлахов

Рафаэль Кәлимуллин

Ренас Кәлимуллин

Раил Сәлахетдинов

Илмир Төхвәтуллин

Руслан Рафыйков

Радик Сәлахов

Фирдүс Зәйнуллин

Милли көрәш

Көрәшчеләр генә түгел, оештыручылар өчен дә җаваплы бәйге булды бу. Нинди генә авырлыклар булмасын, көрәштән баш тартып булмый, диде алар. Батырларның 7се узган елгы уңышын кабатлады.

Хәрәкәтсез булмый

Инде икенче ел рәттән зур ярышлар алдыннан көрәш җәмәгатьчелеге дулкынланып ала: булырмы бу бәйге, булмасмы? Кызганыч, барысы да милли спорт төрен үз итүчеләр теләгәнчә генә килеп чыкмый. Татарстан чемпионатын, мәсәлән, былтыр Яңа ел бәйрәме алдыннан гына уздырырга туры килде. Быелгысының да язмышы башкача булырга мөмкин иде. Шөкер, узды ул. Казанга 40тан артык команда, 320дән артык көрәшче җыелды. «Бик көттек бу ярышны. Бер уйлаганда, бераз тыйнаклык күрсәтеп, бүгенге вазгыятьне сылтау итеп, эшне оештырмаска сәбәп тә бар иде. Әмма көрәш тормышның үзе кебек гел динамик хәрәкәттә, үсештә булырга тиеш. Андый очрашулар, ярышлар туктала икән, көрәшчеләр тынычланып кала. Спортта киеренкелек кирәк», – диде бәйге башланыр алдыннан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Көрәш федерациясе җитәкчесе Марат Әхмәтов.

Кем әйтмешли, тыныч вакытта көрәш буенча зур ярышлар җомга-шимбә көннәрендә уза. Бу юлы бәйге дүшәмбе-сишәмбе булды. Оештыручылар яшереп тормады: бүгенге шартларда халыкның күп җыелмавы хәерле. Әмма ни гаҗәп, тамашачылар саны элеккеге еллардан әллә ни кайтыш булмады. Көрәшне яраткан кеше барыбер йөри милли бәйгеләргә. «Прививкам ясалган, битлегем – кесәмдә. Шуңа күрә куркып тормадым, килдем ярышка. Әлбәттә, сакланырга кирәк. Әмма артыкка китсә, курку барлыкка килә. Бу – үзе авыру инде. Ә мин авырырга теләмим», – диде «ВТ» хәбәрчесенә Казанда яшәүче Мансур абзый.

Ашыккан ашка пешкән

Һәрвакыттагыча, тамашачылар арасында үзләре кайчандыр бил алышуның тәмен татып калган, бүген яшьлеген искә төшереп, «безнекеләр нихәл икән анда» дигән уй белән якташлары өчен җан атып утыручы ир уртасы кешеләр күбрәк иде. Туташлар да аз түгел. Аңлашыла инде, милли көрәшне өзелеп яраткан өчен генә җыелмый алар бирегә. Ни дисәң дә, «Ак барс» көрәш сараена татарның иң асыл егетләре җыелды бу көннәрдә.

Бәйгенең башында ук әнә шул туташларның күңел кылларын тибрәткән, белгечләрне гаҗәпләндергән вакыйгалар аз булмады. Әйтик, быел 65 килолы егетләр арасында көчен сынарга чыккан Раббани Нургалиев, беренче әйләнештә үк оттырып, тамашачылар арасына күчеп утырды. Татар көрәшенең реклама дөньясындагы «йолдыз»ына әверелгән Булат Мусин да шундый язмышка дучар булды. Көндәшлек зур һәм ул ялгышларны кичерми. Ике көн барган ярышта кемнең батыр каласын ахырга кадәр чамалап булмый. Әлбәттә, фараз ясарга була, әмма күп очракта алар тормышка ашмый. Шунысы белән кызык та инде милли спорт төре.

Финал кабатлана

60 килолы егетләр ярышында узган елгы кебек үк чемпион исемен 21 яшьлек Алексей Абрамов яулады. Дөрес, былтыр ул Алексеевск районы өчен бил алышса, быел Лаеш данын яклады. Лаешта көрәшкә игътибар моңарчы булмаган дәрәҗәгә җитте һәм әлеге район командалар ярышында да лидерлар сафына керде. Финалда Алексей Абрамов үзенең якташына әверелгән Шамил Чәвикне көндәше алган өч кисәтү ярдәмендә ота алды. 65 килолы егетләр ярышында да узган елгы чемпион Илназ Миңмуллин батыр булып танылды. Балтач егете хәлиткеч алышта Чистай данын яклаган Илнар Закировтан өстен чыкты. Быелгы финалдагы иң матур очрашуларның берсе булды бу. Егетләр ахырга кадәр көрәште, берсе дә бирешергә теләмәде, әмма батыр исеме бирәү генә була.

«Татар-информ» / Михаил Захаров

Марат ӘХМӘТОВ,
Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Көрәш федерациясе җитәкчесе:

Быелгы бәйге бик матур, зәвыклы булды, тамашачыны үзенә бәйләп торды. Бәхәсләр дә чыкты. Аңлашыла инде, җиңелгән кешенең тиз генә биреләсе килми. Һәркемнең җиңәсе килә. Кызганыч, зал тутырып тамашачы җыя алмадык. Вазгыять тынычлангач, шыплап тутырып килерләр дип өметләнәм. Көрәшле халык – киләчәкле халык. Шул ук вакытта башлыклары – милләттәшләребез, халыкның күбесе татар була торып, кайбер район командалары бәйгегә килмәде. Бу мәсьәләдә алар белән үзем сөйләшәчәкмен. Йөзләре кызарырлык булсын. Чөнки милләт язмышы милли традицияләр, гореф-гадәтләр һәм тел язмышы бергә үрелеп бара. Бу заманда милләт язмышына болай карарга ярамый. Казанда да көрәшне күтәрәсе бар әле. Казаннан ун команда булса да ярый иде. Чаллыны, Әлмәтне үрнәк итеп куярга була. 80–90 мең кеше яшәгән районнарда да көрәш белән шөгыльләнүчеләр күбрәк булырга тиеш.

70 килолы егетләр ярышының финалында Казанның Вахитов районы өчен бил алышучы Ислам Фәлахов әле 20 яшен дә тутырмаган көндәше Рафаэль Билдановка (Әлмәт) бер мөмкинлек тә калдырмады һәм шулай ук икенче ел рәттән чемпион булды. 75 килолы егетләр арасындагы хәлиткеч алышта яшьлек һәм тәҗрибә очрашты: Рафаэль Кәлимуллин белән Ленар Садыйков. Узган ел да шундый ук финал булган иде. Бер генә аермасы бар: былтыр Түбән Кама өчен көрәшкән Рафаэль бу юлы Әлмәт өчен тир түкте. Башта Кәлимуллин җиңеп барды, ул кулын авырттыргач, өстенлек Садыйковка күчте. Әмма Рафаэль барыбер үз дигәненә иреште һәм 22 яшьлек егет икенче ел рәттән чемпион булып танылды.

Узган ел Рафаэль тәүге мәртәбә чемпион булып танылгач, абыйсы Ренас болай дигән иде: «Камиллекнең чиге юк, Рафаэльнең күп нәрсәгә өйрәнәсе, хаталарын төзәтәсе бар әле. Өйгә кайткач сөйләшербез». Еш сөйләшәләр, ахры. Әмма иң үтемлесе – абыйсы күрсәткән үрнәк. Теләче өчен бил алышучы Ренас үзе тыйнакланып тормады, бу юлы да 80 килолылар арасында үзенә тиңнәр юклыгын раслады һәм берничә дистәдән артып киткән җиңүчеләренә чираттагысын өстәде.

Балтачка читләр кирәкми

85 килолы егетләр арасында фаворитлар исемлегендә йөрүче көрәшчеләр аз түгел. Әмма быел җиңү бәхете Кукмарадан Раил Сәлахетдиновка елмайды. Финал алышында ул көндәше Фаяз Зариповка (Теләче) бер балл алырга да мөмкинлек бирмәде. 90 килода Илмир Төхвәтуллинның 7:1 исәбе белән отканын ишеткән кеше, җиңү аңа бик җиңел бирелгәндер, дип уйларга мөмкин. Чынлыкта исә алай түгел. Очрашу тәмамланырга 30 секунд калып барганда, 1:1 иде исәп. Әмма ахырга таба Казан егете тәҗрибәсен «кабызды» һәм Әлмәт көрәшчесе Айрат Сәмигуллинга җиңелүен танырга туры килде. Сүз уңаеннан, Илмир, аягын авырттыру сәбәпле, былтыргы ярышларда катнаша алмаган иде. Хәзер исә янә лидерлар сафына керде.

100 килолы егетләр финалында бер үк район көрәшчеләре – Балтач егетләре очрашты. Моңа аерым игътибар итүнең сәбәбе дә бар. Чөнки Балтач – командага үзләрендә туып-үскән егетләрне генә туплаган сирәк районнарның берсе. Читтән көрәшчеләр чакыру мәсьәләсенә карата фикерләр һәрвакыт төрле булды. Кемдер уңышлы файдалана бу алымны, ә кем өчендер ул вакытлы һәм ахыр чиктә файдасыз чара гына булып кала. Балтач исә өскә таба үз егетләре белән үрмәләргә тырыша. Руслан Рәфыйков белән Рәдис Сәмигуллин арасында узган хәлиткеч алышта исә беренчесе көчлерәк булып чыкты.

Кем ничек күрә бит!

130 килолы егетләр арасындагы ярыш турында кечкенә генә фильм төшереп булыр иде. Көндәшлек башка категорияләрдә дә җитәрлек, әмма Раил Нургалиев, Муса Галләмов, Радик Сәлахов арасындагы алыш беркайчан да тыныч кына тәмамланмый һәм беркемне дә битараф калдырмый. Әлеге авырлык үлчәвендә әле финалга кадәр үк әнә шуңа тиң берничә очрашу була. Бу юлы Нургалиев белән Сәлаховка иртәрәк очрашырга насыйп булды. Әкияттәге кебек бик озак алышты алар. Үзләре дә кызды егетләр, тамашачыны да урыныннан торгыздылар. Ә иң авыры, гадәттәгечә, хөкемдарларга булды. «Без монда барысын да күрәбез, кирәк икән, кабатлап карый алабыз», – дип кисәтте алар. «Юк, өстән яхшырак күренә, белмәгәнне әйтмибез», – дип кырт кисте җанатар халкы. Нишләмәк кирәк, заманасы шундый. Хәзер тамашачының да алышларны телефонына төшереп, яңадан карау мөмкинлеге бар. Җитмәсә, быелгы бәйгене «Ютуб» каналы аша да күрсәтеп бардылар. Тик анда кем ничек күрә бит! Ахыр чиктә Раил 3 кисәтү алды, Радикны исә җиңүче дип таныдылар. «Гаделлек бар ул дөньяда!» – дип кычкырды Сәлахов. Быел кабат туган ягы Теләче өчен бил алыша башлаган Нургалиев исә урынына барып утырды да, сүрелеп бетә алмыйча, кабат хөкемдарлар һәм федерация җитәкчеләре янына килде. Әлеге дә баягы телефон карадылар, әмма һәркем үз фикерендә калды. Кем ничек күрә бит!

Финалда исә Радик Сәлахов Лаеш өчен бил алышырга чыккан Муса Галләмов белән очрашты. Кызганыч, Муса аягын авырттыргач, очрашу вакытыннан алда тәмамланды. Келәмгә чыгарга талпынып караса да, Галләмовка бу адымга бармаска киңәш иттеләр. Ә бит... Хәер, анысы турында бераз соңрак. Чемпион исемен исә янә Радик Сәлахов яулады.

Татарстанның быелгы чемпионаты авырлыгы 130 килодан арткан егетләр арасындагы алыш белән тәмамланды. Бу юлы да чемпион исемен Яшел Үзәннән Фирдүс Зәйнуллин яулады. Финалда ул Чаллыдан Ранис Гыйлаҗетдиновны җиңде. Нәкъ менә Чаллы көрәшчеләре командалар беренчелеген оттылар да инде. Алардан нибары 0,5 баллга калышып, Лаеш икенче булды. Их, Муса аягын авыттырмаган булса! Әлмәт егетләре өченче урынны алды.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Җиңүчеләр исемлеге

60 кило
1 урын – Алексей Абрамов (Лаеш)
2 урын – Шамил Чәвик (Лаеш)
3 урын – Динар Миңнебаев (Яңа Чишмә)
3 урын – Раил Вәлиев (Казан/Яңа Савин)

65 кило
1 урын – Илназ Миңмуллин (Балтач)
2 урын – Илнар Закиров (Чистай)
3 урын – Искәндәр Мортазин (Әлмәт)
3 урын – Дмитрий Левашев (Чаллы/Комсомол)

70 кило
1 урын – Ислам Фәлахов (Казан/Вахитов)
2 урын – Рафаэль Бильданов (Әлмәт)
3 урын – Илназ Димиев (Мамадыш)
3 урын – Рамил Камалов (Баулы)

75 кило
1 урын – Рафаэль Кәлимуллин (Әлмәт)
2 урын – Ленар Садыйков (Чаллы/Комсомол)
3 урын – Динар Кәримуллин (Лаеш)
3 урын – Фирдүс Галимуллин (Балтач)

80 кило
1 урын – Ренас Кәлимуллин (Теләче)
2 урын – Марат Кәримов (Әлмәт)
3 урын – Габделфәт Хәйруллин (Лаеш)
3 урын –Илшат Таһиров (Минзәлә)

85 кило
1 урын – Раил Сәлахетдинов (Кукмара)
2 урын – Фаяз Зарипов (Теләче)
3 урын – Ренат Шәйхетдинов (Чаллы/Комсомол)
3 урын – Максим Степанов (Мамадыш)

90 кило
1 урын –Илмир Төхвәтуллин (Казан/Яңа Савин)
2 урын – Айрат Сәмигуллин (Әлмәт)
3 урын – Фәрис Хуҗин (Актаныш)
3 урын – Илнар Галимов (Алабуга)

100 кило
1 урын – Руслан Рәфыйков (Балтач)
2 урын – Рәдис Сәмигуллин (Балтач)
3 урын – Эльдар Хәмитов (Чаллы/Комсомол)
3 урын – Булат Кәримуллин (Актаныш)

130 кило
1 урын – Радик Сәлахов (Әлмәт)
2 урын – Муса Галләмов (Лаеш)
3 урын – Руслан Газизуллин (Лаеш)
3 урын –Эльмир Ахунҗанов (Мамадыш)

130+
1 урын – Фирдүс Зәйнуллин (Яшел Үзән)
2 урын – Рәнис Гыйләҗетдинов (Чаллы/Комсомол)
3 урын – Илфат Гыймадиев (Нурлат)
3 урын – Рөстәм Бәдретдинов (Минзәлә)

Командалар беренчелеге

1. Чаллы
2. Лаеш
3. Әлмәт
4. Балтач
5. Мамадыш

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7404 данә
Гомуми тираж – 17211 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 371

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+